# ЧИШМӘ БАШЫ

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
МӨНДЕШ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе
АПРЕЛЬ
2026 ел № 16




***Ата-аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы***

Газетаның сәхифәләре:

* Сертотмас үрдәк маҗаралары.
* ЭкоЯз 2026
* Без – бәйге җиңүчеләре!
* 25 апрель – Эколяталар туган көн.
* Татарча диктант 2026!

Баш мөхәррир:
балалар бакчасы мөдире
Мостафина Р.Г.
Мөхәррир урынбасарлары:
музыка җитәкчесе Хөсәенова Г.Ф.
тәрбиячеләр: Хөсәенова Р.Р., Җәләлиева А.Г.,
Хөсәенова В.В., Шәкүрова Р.С.

## “Сертотмас үрдәк маҗаралары”

6 нчы апрельдә бакчабызда юл йөрү кагыйдәләренә багышланган “Сертотмас үрдәк маҗаралары” исемле чара булып узды.

Чараның **максаты:** юл хәрәкәте билгеләре турында күзаллауларны формалаштыру. Үз-үзеңнең, тирә-юньдәгеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү, юл йөрү кагыйдәләренә хөрмәт белән карау, аралашу культурасы тәрбияләү.

Чара барышында балалар белән сертотмас үрдәкне юл йөрү кагыйдәләренә өйрәттек, кызыклы уеннар уйнадык, җырладык. Бакчабызга кунак булып Арча районы ГБУ “БДД” профилактика бүлеге җитәкчесе Мухаметзянова Энҗе Газизовна килде. Чара ахырында юлларда игътибарлы булырга, юл кагыйдәләрен бозмаска, аларны үтәргә кирәклеге турында искәртте һәм истәлекле бүләкләр тапшырды.







## 1 апрельдән 24 майга кадәр Татарстан Республикасында «Эковесна-2026» конкурсы башланды.

Апрельнең 1 нче атнасында, халыкара кошлар көне уңаеннан, бакчабызда “Кошлар - безнең дусларыбыз” исеме астында танып-белү сәгате үткәрелде.



"ЭКОЯЗ-2026"ның  2 нче атнасы "Кайгырту" девизы астында уза. Бакчабызда "Хайваннарга ярдәм ит" игелек сәгате узды.



ЭКОЯЗ-2026" республика конкурсының 3 нче атнасында "Экологик ильһам калейдоскобы" (икенчел чималдан рәсемнәр һәм кул эшләре ясау) узды.







«Экояз-2026» акциясенең 4 нче атнасы — «Табигать язмышы безнең кулларда». Апрель уртасы — җир тын алган, кояш җылыткан матур чак. Без бу көннәрне бушка уздырмадык. Җимеш агачлары утырттык. Агачлар утырту – изге гамәл, дип, юкка гына әйтмиләр бит. Территорияларне санитар чистарту икеайлык кысаларында, бакчабызда кар тарату, участокны чүптән арындыру эшләре башкарылды.

**25 апрельдә, һәр елны, Бөтенроссия күләмендә “День эколят» исеме астында табигатьне саклауга багышланган проектлар тормышка ашырыла.**

Безнең балалар бакчасында бу көнне әлеге көнгә багышланган чаралар уздырылды. Бу көнне балалар әкият герройлары Шалун, Умница, Тихоня һәм Елочка белән табигатьне кайгыртырга, сакларга өйрәнделәр. Табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен искә төшерделәр. Викторина ярдәмендә табигать турында белемнәрен ныгыттылар, рәсемнәр ясадылар.









**Шушы көннәрдә Арча шәһәренең балалар бакчаларында бөек шагыйребез Г. Тукайның тууына 140 елга  багышланган "Шигъриятнең якты йолдызы" исемле районкүләм шигырь сөйләүчеләр бәйгеләре узды.**

Бәйгедә безнең балалар бакчасының мәктәпкә әзерлек төркемендә тәрбияләнүче Әнвәр Хөсәинов чыгыш ясап, 2 нче урынга, ә 3-4 яшьлекләр арасында Ралинә Камалиева 1 нче урынга лаек булдылар. Котлыйбыз! Киләчәктә уңышлар телибез!



















**«Татарча диктант» Бөтенроссия акциясенә Мөндеш балалар бакчасы коллективы һәм башлангыч мәктәп укытучылары да кушылды.**

Быел ул бөек шагыйребез Г.Тукайның тууына 140 елга багышланды. Диктант язучыларга Габдулла Тукайның «Бәхет» мәсәле тәкъдим ителде. Быел текстны музыка җитәкчесе Гөлшат Хөсәенова  укыды. Соңыннан балалар бакчасы коллективына диктант язуда катнашкан өчен Рәхмәт хатлары тапшырылды.





